Исполнительный комитет
Камаевского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан

423643,РТ, Менделеевский район,
с.Камаево, ул. Дифгата Сирая д.29А

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге
башкарма комитеты

423643 , РТ, Менделеевск районы,
Камай авылы, Дифгать Сирай урамы
29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

От 2019 ел 24 нче декабрь № 23

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Камай авыл җирлеге территориясендә
халык тарафыннан пиротехник эшләнмәләр
куллану урыннарын билгеләү турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 25.04.2012 ел, № 390 «Янгынга каршы режим турында " ,Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Пиротехник эшләнмәләрне таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында» 2009 елның 22 декабрендәге 1052 номерлы карары нигезендә һәм Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү чорында бәхетсезлек очракларын булдырмау максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Куллану өчен махсус белем һәм күнекмәләр таләп ителми торган , I - III класслы көнкүреш билгеләнешендәге пиротехника әйберләрен (ГОСТ Р 51270-99) халык тарафыннан куллану урыны итеп Камай авылы – Тынычлык урамы 26А йорты янындагы мәйданны билгеләргә.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм www.mendeleevsk.tatarstan.ru Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтының «Камай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Камай авыл җирлеге башлыгы: И.И.Әһлиева